
Сөмбелә бәйрәме
Исәнме, Көз, алтын көз,
Безне сагынып килдеңме?
Агачларга куакларга
Сары чуклар элдеңме?

**Елнын сихри фасылында, көн белән төн тигезләшкән мәлдә, татар халкы Сөмбелә бәйрәмен үткәргән. Ул – көзге бәйрәм, уңыш бәйрәме. Сөмбелә - ул "башак" дигән сүз. Җитен чәчле, зәңгәр күзле, зифа буйлы, сүзгә тапкыр, эшкә уңган кызны да Сөмбелә дигәннәр.**





**Көз килде дә керде өйгә,**
**Яфраклар йөгерәләр.**
**Ышык эзләп койма, капка**
**Асларына керәләр.**

**Утром мы во двор идём,**
**Листья сыплются дождём.**
**Под ногами шелестят**
**И летят, летят, летят..**



**Яфрак бәйрәме**

*Р.Еникеева музыкасы, Л.Лерон сүзләре*

**Яңгыр түгел, кар да түгел,**
**Яфраклар ява җиргә.**
**Көз турында җырлыйм әле**
**Кушыл син яңа җырга.**

*Кушымта:*

**Сары, сары, сап-сары**
**Агачның яфраклары.**
**Җил исә, ява яфрак**
**Көзнең матур чаклары**

**Оча яфрак, уйный яфрак,**
**Һаваларда әйләнеп.**
**Бүген, бүген, бүген, бүген**
**Яфракларның бәйрәме!**



Кәрзин тулы алмалар,
Помидор һәм кыярлар,
Кәбестә, кишер, суган,
Алтын көз безнең уңган.

**Яңгыр**

*Татар халык уен җыры*

**Әй алма, алма, алма,**
**Алма алмаланганда.**
**Алмаларга рәхәт була**
**Яңгыр тамгалаганда.**
**Әй кыяр, кыяр, кыяр,**
**Кыяр кыярланганда.**
**Кыярларга рәхәт була**
**Яңгыр коеп яуганда.**
**Әй шалкан, шалкан, шалкан,**
**Шалкан шалканланганда.**
**Шалканнарга рәхәт була**
**Яңгыр шаулап яуганда.**
**Кәбестәсен, помидорын,**
**Җиләген, алмаларын**
**Тәрбияләп үстерегез,**
**Күрерсез файдаларын.**





# "Зур шалкан" әкияте





## Гөмбәчеләр җыры

*Татар халык көе, Г. Гыйләҗетдинова сүзләре*

Урмандагы аланда
Тәмле гөмбәләр үсә.

Кушымта:

Әйе шул, әйе шул,
Тәмле гөмбәләр үсә.
Әйлән-бәйлән йөрибез,
Күңел ачып уйныйбыз.

Кушымта:

Әйе шул, әйе шул,
Күңел ачып уйныйбыз.
Яфрак астына качып
Утыра алар посып.

Кушымта:

Әйе шул, әйе шул,
Утыра алар посып